**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Үчәлле авылы №52 1 март, 2017 ел

“Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең норматив хокукый актларына һәм җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе турында” 2010 елның 10 ноябрендәге 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында (29.02.2012 № 37 карар редакциясендә)

"Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында" 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы "Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында" карары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең Уставы нигезендә,

Үчәлле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең норматив хокукый актларына һәм җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе турында” 2010 елның 10 ноябрендәге 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында (29.02.2012 № 37 карар редакциясендә) түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә рекомендация характерында була һәм ул җибәрелгән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлегенең җирле үзидарә органы тарафыннан аны алганнан соң 30 көн эчендә һичшиксез каралырга тиеш. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырган гражданга яисә оешманы карау нәтиҗәләре буенча, дәлилләнгән җавап җибәрелә (бәяләмәдә ачыкланган коррупциоген факторлар турында мәгълүмат булмаган очраклардан яисә ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү ысулы турындагы тәкъдимнәрдән тыш), анда коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен һәм (яисә) норматив хокукый актта ачыкланган коррупциоген фактор белән килешмәү сәбәпләрен исәпкә алу чагылдырыла. "

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.М.Төхвәтуллина